| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ УЛЬЯНКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 нче декабрь Ульянково авылы №15

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Ульянково авыл җирлеге
территориясендә фейерверклар үткәрү өчен
мәйданчыклар билгеләү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 19 нчы статьясына, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Ульянково авыл җирлеге территориясендә салютлар һәм фейерверклар оештыру һәм үткәрү, җәмәгать урыннарында пиротехник эшләнмәләрне куллануны, халыкның иминлеген, инфраструктура объектларын тәэмин итү, массакүләм чаралар үткәрүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Пиротехник чаралар (эшләнмәләр) куллану өчен мәйданчыклар билгеләргә (1нче кушымта).


2.Гражданнар тарафыннан көнкүреш пиротехника әйберләрен куллану буенча инструкцияне һәм белешмәлекне мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карарны Уставта билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ульянково авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ф. А. Сундурова

Ульянково авыл җирлеге
Башкарма комитетының
11.12.2019 елның 15 нче карарына
1 нче кушымта




Площадка для запуска фейерверков расположена на горе на расстоянии 700 метров от нас.пункта Ульянково в восточном направлении . На расстоянии 400 метров в южном направлении от площадки протекает река. В западном направлении на расстоянии 300 метров глубокий овраг. Рядом с площадкой зданий не имеется. С восточной стороны от площадки поле